**Класс:** 5

**Укытучы:** Шакирова Рузилә Рәисовна

**Программа:** Вигасин А.А. Гомуми тарих. Борынгы заман тарихы. 5 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы / - Казан: Татар.кит. нәшр., 2020.

**Тема:** Рим республикасының төзелеше

**Максаты**: Рим консулларының сайлану һәм эшләү максатларын ачыклау; Рим гаскәренең төзелеше белән таныштыру; укучыларда тарих фәненә кызыксыну тәрбияләү.

**Планлаштырылган нәтиҗә:** карта белән эш, яңа терминнарны үзләштерү.

I **лекция**

**Исәнмесез, укучылар! Бүгенге дәрестә Рим республикасының төзелеше турында сөйләшербез. (2 слайд)**

План:

- Консуллар сайлау һәм кануннар кабул итү
- Сенат һәм Римда аның роле
- Рим гаскәре

**(3 слайд)** Ике йөз елга сузылган көрәш нәтиҗәсендә плебейлар Римның тулы хокуклы гражданнары булуга ирешкәннәр. Консулларны һәм башка җаваплы кешеләрне хәзер патрицийлар арасыннан да, плебейлар арасыннан да сайлыйлар.

**Укучылар, кемнәр булган соң ул плебейлар һәм пратрицийлар? Әйдәгез аңлатма биреп китик**.

**(4 слайд) Патрицийлар** – Римга нигез салучыларның варислары. **Плебейлар** – Римга Италиянең башка өлкәләреннән күчеп килүчеләр. Плебейлар патрицийлар белән бергә законнар кабул итәләр. Араларында ярлылар күп булган плебейлар өчен б.э.к. 326 елда бурыч коллыгын бетерү аеруча зур әһәмияткә ия була.

**(5 слайд)** Ел саен җәйге матур таңнарның берсендә Рим гражданнары шәһәр диварлары артындагы киң мәйданда – Марс кырына җыйналганнар. Тибрның биек ярларында кызыл әләм җилфердәп торган, ул Римга читтән бернинди дә басып алу куркынычы янамавын белдергән. Шәһәр капкаларыннан консул чыкканы күренгән, аны унике ликтор озата килгән. (Ликтор сакчы дигәнне аңлаткан.) Боргы тавышы яңгыраган. Каһиннар аллаларның корбаннары мәрхәмәт белән кабул итүләре турында белдергәннәр. Киләсе елга консуллар сайлау шулай башланган.

**(6 слайд)** Һәр гражданга үзе тавыш бирергә тиешле кешенең исемен язар өчен махсус такта бирелгән. Тавыш бирүче, тар басмалар аша үткәндә, ул такталарны махсус кәрзингә ташлаган. Тавышларны санагач, яңадан быргы уйнаган, җиңүчеләрнең исемнәре игълан ителгән.

**Укучылар, сез ничек уйлыйсыз, кемнәр консул булып сайлана алган соң? (7 слайд)** Бай кеше дә, ярлы гражданнар да консул булып сайлана алган. Әмма Римда дәүләт эшләрен башкарган өчен хезмәт хакы түләмәгәннәр, шуңа күрә гадәттә бай патриций һәм плебейлар гына консул була алган.

**(8 слайд)** Алар чиратлашып Халык җыелышында рәислек иткәннәр, гаскәр туплаганнар, яңа законнар тәгъдим иткәннәр. Аларның һәрберсе икенчесенең карарын юкка чыгара алган. Шуңа күрә алар һәрвакыт үзара килешеп эшләргә тиеш булганнар. Сугыш вакытында консулларның берсе гадәттә Римда калган, икенчесе походка киткән. Әгәр куркыныч зур икән, сугышта икесе дә катнашканнар. Бу очракта алар көн саен алмашып, чиратлашып командалык иткәннәр.

**(9 слайд)** Халык трибуналарын сайлау һәм кануннар кабул итү өчен римлылар еш кына шәһәрнең үзәк мәйданына – Форумга

җыйналганнар. Җыелышта яңа кануннар тәкъдим итеп бары тик җаваплы кешеләр – консуллар, халык трибуннары гына чыгыш ясый алган. Калган гражданнар фикер алышмыйча гына бу законны яклап яки каршы чыгып тавыш биргәннәр. Ләкин халык трибуннарының берсе, әгәр тәкъдим ителгән канунны зарарлы дип санаса, тавыш бирүне тыя алган.

**(10 слайд)** Плебейлар һәм патрицийлар арасында барган көрәш нәтиҗәсендә сенатка сайлауда да үзгәрешләр килеп чыккан. Аңа бернинди сайлауларсыз элекке консуллар, халык трибуннары һәм башка җаваплы кешеләр эләккән. Алар барысыда гомер буе сенат әгъзасы булганнар.

**(11 слайд)** Сенат барлыгы өч йөз кешедән торган һәм гаять зур хакимияткә ия булган: казна белән идарә иткән, сугыш алып бару планнарын караган, башка дәүләтләр белән сөйләшүләр алып барган. Римда судьялар бары тик сенаторлар була алган. Сенат үз эшләре хакында беркем алдында да җавап тотмаган һәм ялгыш карарлары өчен җавап бирмәгән.

**(12 слайд)** Гадәттә сенат утырышларын консул алып барган. Фикер алышулар вакытында ул күпчелек сенаторлар хуплаган фикергә, алар белән килешмәсә дә, бик сирәк каршы чыккан. Чөнки бер ел үткәч үзе дә сенаторга әйләнәчәген һәм гомерлек сенатор булачагын белгән. Үзләренә каршы чыккан өчен башка сенаторлар аны беркайчан да гафу итмәячәкләрен аңлаган.

**(13 слайд)** Туктаусыз сугышлар нәтиҗәсендә римлылар легионнарга (4 меңләп сугышчыдан торган гаскәри бүлекләр) бүленгән, зур һәм сугышчан гаскәр булдырганнар. Сугышчы–легионерлар күбесенчә игенчеләрдән торган; җире булмаган ярлыларны хәрби хезмәткә алганнар.

**(14 слайд)** Легионнар һәркайсы 10 ар отрядтан торган өч саф булып төзелгәннәр. Беренче сафта хәрби хезмәткә чакырылу яшендәге егетләр, икенчесендә – өлкәнрәк һәм көчлерәкләре, ә өченчесендә – иң ышанычлы, сугышларда чыныккан солдатлар баскан. Аларның күбесенең инде чәчләренә чал кергән, йөзләрендә яра эзләре күренеп торган.

**(15 слайд)** Сугышны беренче булып җиңел коралланган сугышчылар башлаган. Аннан соң сугышка беренче линия отрядлары кергән. Әгәр консул аларның дошманны җиңә алмаячагын күрсә, икенче сафтагы отрядлар арасына чигенергә боерган. Сугышка шушы отрядлар кергән. Әгәр дә инде алар да уңышка ирешә алмаса, бер - бер артлы өченче сафка чигенгәннәр.

**(16 слайд)** Монсындагы сугышчылар, чигенүчеләрне үз араларына кертеп, тагын да тыгызланып басканнар һәм тоташ стена булып дошман өстенә ябырылганнар. “Бу дошман өчен иң куркынычы булып чыккан, - дип язган Рим тарихчысы Тит Ливий. - Чөнки алар чигенүчеләрне куабыз дип уйлаганнар, ә каршыларына кинәт кенә яңа, элеккедән дә зуррак саф калкып чыгуын күргәч, югалып калганнар.”

**(17 слайд)** Кул сугышларында легионерларның кыска кылычлары куркыныч коралга әверелгән. Сугыш вакытында җәяүлеләрне фланглардан атлы гаскәр саклаган, ә җиңә башлагач ул качып баручы дошманны эзәрлекләгән.

**(18 слайд)** Яуда бер генә төнгә тукталганда да римлылар ныгытылган лагерь корганнар. Ул һәрвакыт бер план буенча дүртпочмак рәвешендә төзелгән. Сугышчылар, коралларын салып, лагерь тирәли чокыр казыганнар (валлар), туфракны өеп, аны казыклар белән ныгытканнар. Аннары гаскәр башлыгы чатырын һәм сугышчыларның чатырын корганнар. Лагерь ял итүче гаскәр өчен ышанычлы ныгытмага

әверелгән. Көтелмәгән тревога вакытында да ыгы-зыгы килеп чыкмаган. Һәр сугышчы үзенә нәрсә эшләргә кирәклеген белеп торган.

**(19 слайд)** Рим армиясе дисциплиналы булуы белән дан казанган. Әгәр хәрби часть куркаклык күрсәтсә, аның сугышчыларын төзеп бастырганнар да, һәр унынчы сугышчыны җәзага тартканнар. Әгәр сакчы үз постында йокыга китсә, аны ташлар белән бәреп үтергәннәр. Сугышта батырлык күрсәтүчеләргә табышны күбрәк биргәннәр, мактауны корал белән бүләкләгәннәр. Дошман ныгытмасының диварына беренче булып күтәрелгән кешегә тиешле дивар рәсеме төшерелгән такыя биргәннәр.

**II практик өлеш**

**Беренче бирем**

***Таблицадагы бирелгән аңлатмалар белән терминнарны тәңгәл китереп җыегыз.***

| | |
|---|---|
| Патрицийлар | Римга Италиянең башка өлкәләреннән күчеп килүчеләр |
| Плебейлар | Римның төп халкы |
| Ликтор | сугышчы |
| Легионер | сакчы |

**Җавап:**

| | |
|---|---|
| Патрицийлар | Римның төп халкы |
| Плебейлар | Римга Италиянең башка өлкәләреннән күчеп килүчеләр |

| | |
|---|---|
| Ликтор | сакчы |
| Легионер | сугышчы |

**Икенче бирем**

***Тексттагы тарихи хаталарны табыгыз***

Б.э.к. III (3) гасырда патрицийларны барлык хезмәт урыннарына сайлый башлаганнар, ә менә плебейлар халык трибуны була алмаганнар. Моннан соң плебейларга, патрицийлар белән бергә, сугышта басып алынган “җәмәгать жире” кишәрлекләре бирелгән, бурыч коллыгы тыелган. Бу патрицийларның тулы хокуклы Рим гражданнарына әверелүен күрсәткән.

**Җавап:**

Б.э.к. III (3) гасырда ~~патрицийлар~~ **плебейларны** барлык хезмәт урыннарына сайлый башлаганнар, ә менә ~~плебейлар~~ **патрицийлар** халык трибуны була алмаганнар. Моннан соң плебейларга, патрицийлар белән бергә, сугышта басып алынган “җәмәгать жире” кишәрлекләре бирелгән, бурыч коллыгы тыелган. Бу ~~патрицийларның~~ **плебейларның** тулы хокуклы Рим гражданнарына әверелүен күрсәткән.

**Өченче бирем**

**Буш калган урыннарга аста күрсәтелгән сүзләрне куеп, текстны языгыз:**

_______ диктатордан кала теләсә кайсы _____ яисә вазифалы затның күрсәтмәсен, боерыгын юкка чыгара алганнар. Моның өчен халык трибуны бер генә сүз әйткән: “ _______” Халык трибуны шәхесе кагылгысыз булып саналган, аны үтерү иң авыр _______ берсе булган.

**Сүзләр:** Консулның, җинаятьләрнең , Вето! (Тыям!)  , трибуннар

**Җавап:**

**Трибуннар** диктатордан кала теләсә кайсы **консулның** яисә вазифалы затның күрсәтмәсен, боерыгын юкка чыгара алганнар. Моның өчен халык трибуны бер генә сүз әйткән:” **Вето!** (Тыям!)” Халык трибуны шәхесе кагылгысыз булып саналган, аны үтерү иң авыр **җинаятьләрнең** берсе булган.

**Дүртенче бирем**

**Дөрес җавапны тап:**

**Римда консуллар сайлый торган урын ничек аталган?**

1)Агора

2)сенат

3)Марс кыры

4)Форум

**Җавап:**

3) Марс кыры

**Бишенче бирем**

**Иҗади бирем.**

*Тема текстын кулланып, Рим легионеры исеменнән хикәя язарга.*